КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 21 гыйнвар г.Казань № 20

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Салым салу базасын киңәйтү максатларында хокуклары теркәлмәгән күчемсез милек объектларына һәм җир кишәрлекләренә инвентаризация үткәрү буенча ведомствоара эшче төркем төзү турында» 2017 ел, 13 апрель, 223 нче карары белән расланган Салым салу базасын киңәйтү максатларында хокуклары теркәлмәгән күчемсез милек объектларына һәм җир кишәрлекләренә инвентаризация үткәрү буенча ведомствоара эшче төркем составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Салым салу базасын киңәйтү максатларында хокуклары теркәлмәгән күчемсез милек объектларына һәм җир кишәрлекләренә инвентаризация үткәрү буенча ведомствоара эшче төркем төзү турында» 2017 ел, 13 апрель, 223 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 18 сентябрь, 848 нче; 2020 ел, 23 гыйнвар, 20 нче; 2020 ел, 21 декабрь, 1170 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Салым салу базасын киңәйтү максатларында хокуклары теркәлмәгән күчемсез милек объектларына һәм җир кишәрлекләренә инвентаризация үткәрү буенча ведомствоара эшче төркем составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

эшче төркем составыннан О.С.Кузьминаны чыгарырга;

эшче төркем составына Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары Лилия Мөхәммәт кызы Нәбиуллинаны (килешү буенча) кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин